**СОВЕТ ЛЕНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

ул. 40 лет Победы д. 32,
с. Ленино, 423181

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЛЕНИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

Җиңүнең 40 еллыгы урамы, 32,
Ленино авылы, 423181

тел.: (8-4348) 3-44-16, факс: (8-4348) 3-44-10; Lenin.nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль
районы Ленино авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2022 елның 28 феврале №22-60

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленин авыл җирлеге Советының 2018 елның 1октябрендәге 51-99 номерлы “Даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче затларга акчалата бүләкләүләр, Яңа Чишмә муниципаль районы Ленин авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләмнәрен һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында "гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 17 ноябрендәге 1087 номерлы «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренә, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләр хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Ленин авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленин авыл җирлеге Советының 2018 елның 1 октябрендәге 51-99 номерлы «Даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче затларга акчалата бүләкләүләр, Яңа Чишмә муниципаль районы Ленин авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары, айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләмнәрен һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» гы карарына (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленин авыл җирлеге Советының 2018 елның 14 декабрендәге 54-107 номерлы, от 15.06.2020 №74-150, от 22.10.2020 №3-9, от 16.12.2020 №5-12, от 27.08.2021 №15-39, от 29.12.2021 №19-51)) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- 2 пунктны әлеге карарның 1 нче кушымтасында түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Хезмәт өчен түләүнең уникенче төркемөнә кертелгән авыл җирлекләре булып торучы муниципаль берәмлекләр башлыкларына ай саен акчалата бүләк һәм еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләүдән тыш, ай саен акчалата бүләк, эш нәтиҗәләре буенча елына 6,72 айлык акчалата бүләк нормативыннан артмаган премияләр дә өстәмә түләнергә мөмкин. Аларның урынбасарларына ай саен акчалата бүләкләүдән тыш, елына 6,64 айлык акчалата бүләк нормативыннан артмаган күләмдә ай саен акчалата бүләк түләнә.».

2. Билгеләргә, дип:

әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә;

әлеге карарның гамәлдә булуы, 1.4 пункттан тыш, 2021 елның 4 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла. гамәлдә булуы 2018 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә әлеге карарның 1 өлеше кагыла.

3. Әлеге карарны <url>//pravo.tatarstan.ru веб-сайты буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының http://novosheshminsk.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә
муниципаль районы Ленино
авыл җирлеге башлыгы М.Г.Дубровина